РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОИКШУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422066, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Старая Икшурма,ул.Ленина,д.17
тел.8 (84362) 41-6-47

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ИКШЕРМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422066, Татарстан Республикасы, Саба районы, Иске Икшермә авылы, Ленин урамы, 17 йорт
тел.8 (84362) 41-6-47

e-mail: sik.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

23.04.2019 — № 28

Саба муниципаль районы Иске Икшермә
авыл җирлеге җирле үзидарә органнары
тарафыннан күрсәтелүче муниципаль
хезмәтләр исемлеген раслау турында

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатында, Татарстан республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелүче муниципаль хезмәтләр исемлеген расларга.
2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге башкарма комитетының 15.06.2011 елгы №17 "Җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелүче муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында" карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/rikshurma, җирлекнең информацион стендларында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз естемдә калдырам.

Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгы — Н.Н.Нурмухаметов

Иске Икшермә авыл җирлеге
башкарма комитетының
23.04.2019 елгы №28
карары белән РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелүче дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге

| | |
|---|---|
| 1 | Адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару |
| 2 | Документларның күчермәләрен һәм алардан өземтәләрнең дереслеген раслау |
| 3 | Нотариаль гамәлләр кылу: васыятьнамә яки ышанычнамәләрне раслау |
| 4 | Белешмәләр (еземтәләр) бирү |
| 5 | Агачлар яки куаклыкларны кисәргә, тепләргә яки утыртырга рехсәт бирү |
| 6 | Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу |
| 7 | Муниципаль торак фондыннан гражданга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү |
| 8 | Муниципаль торак фондындагы торак урыннарын гражданнарга хезмәт торак урынын найм шартнамәләре буенча бирү |
| 9 | Тезелеп беткән территорияләрне үстерү өчен җир кишәрлекләре бирү |
| 10 | Торак тезелеше максатларында аны комплекслы үзләштерү өчен муниципаль милектә булган җирләрдән җир кишәрлеген арендалау шартнамәләрен төзү хокукын сату буенча торглар оештыру һәм үткәрү |
| 11 | Күчемсез милек объектларына муниципаль милек реестрыннан өземтә бирү |
| 12 | Җирлектәге муниципаль милектәге биналарны, корылмаларны һәм торак булмаган биналарны арендага бирү |